КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 август г.Казань № 995

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясен раслау турында» 2021 ел, 17 май, 344 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 23 май, 628 нче; 2023 ел, 22 июнь, 736 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәдәниятне үстерү стратегиясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Стратегия паспортының «Стратегияне гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләре» юлының уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыклары объектлары реестрына кертелгән матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларының өлешен 12 тапкырга арттырырга»;

I бүлекнең унсигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыгы (алга таба – матди булмаган этномәдәни байлыгы) – Татарстан Республикасының этник берлекләргә хас булган, буыннан буынга тапшырыла торган, аларда бердәйлекне аңлау хис-тойгысын формалаштыра торган һәм яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрне һәм аларны чагылдыру формаларын, шулай ук әлеге яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрне һәм аларны чагылдыру формаларын торгызуны һәм аларның заманча үсеш тенденцияләрен колачлый торган рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләр җыелмасы буларак Татарстан Республикасы төп халыкларының матди булмаган мәдәни мирасы;»;

III бүлектә:

3.1 бүлекчәдә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының нәтиҗәле социаль-икътисадый үсеш өчен бай мәдәни ресурслары бар: тарих һәм мәдәният һәйкәлләре, матди һәм матди булмаган этномәдәни байлык, территориянең архитектура төзелеше, күренекле урыннар, халык кәсепләре һәм һөнәрләре, сәнгать иҗатының традицион төрләре һәм фольклор, һөнәри сәнгать һәм эксперименталь иҗат, дөньякүләм масштабта танылган мәдәни-тарихи брендлар.»;

кырык җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Традицион мәдәниятнең кыйммәтле үзәге – матди булмаган этномәдәни байлык. Татарстан Республикасы җирле халыкларының матди булмаган мәдәни байлыгын актуальләштерү һәм өйрәнү Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәр халыкның мәдәни тиңдәшлеген саклап калу өчен, мәдәниара диалогны булдырып тору өчен кирәк.»;

3.3 бүлекчәдә:

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыгы объектларын ачыклауга, өйрәнүгә, файдалануга, актуальләштерүгә, саклап калуга һәм популярлаштыруга эшчәнлеге юнәлдерелгән мәдәният оешмалары һәм дәүләткә карамаган мәдәният институцияләре эшчәнлеген фәнни, методик яктан һәм кадрлар белән тәэмин итүне камилләштерү.»;

егерме сигезенче абзацта «мирасы» сүзен «этномәдәни байлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 бүлекчәнең унөченче абзацында «мәдәни мираска» сүзләрен «этномәдәни байлыкка» сүзләренә алмаштырырга;

VII бүлекнең уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыклары объектлары реестрына кертелгән матди булмаган этномәдәни байлыклар объектларының өлешен 12 тапкырга арттырырга.»;

VIII бүлекнең 3.8 пунктындагы 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Ачыкланган матди булмаган мәдәни мирас объектларының гомуми саныннан Татарстан Республикасының матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестрына кертелгән матди булмаган этномәдәни байлык объектлары өлеше, процент».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында» 2021 ел, 24 декабрь, 1285 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 декабрь, 1422 нче; 2023 ел, 20 март, 286 нчы; 2023 ел, 17 июль, 840 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 – 2028 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиягә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VIII бүлекнең 8.2 бүлекчәсендәге икенче абзацында «мираска» сүзен «этномәдәни байлыкка» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Стратегиягә кушымтаның 7.4 пунктында:

«Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу өлкәсендә инновацияле эш программаларын һәм эш технологияләрен гамәлгә ашыру» юлында:

3 графада «Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның матди булмаган мәдәни мирасын» сүзләрен «Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыгын» сүзләренә алмаштырырга;

5 графада «матди булмаган мәдәни мирасны» сүзләрен «Татарстан Республикасының матди булмаган этномәдәни байлыгын» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы халыкларының матди булмаган мәдәни мирасы объектлары реестрын булдыру һәм үстерү» юлында:

3 графада «халыкларының матди булмаган мәдәни мирасы» сүзләрен «матди булмаган этномәдәни байлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

5 графада «халыкларның матди булмаган мәдәни мирасы» сүзләрен «матди булмаган этномәдәни байлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин